| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.02.2018 г.Казань № 3

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 24 гынварендә теркәлде, № 4536

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "2017 елда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында" 2017 елның 13 февралендәге 74 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының аерым дәүләт казна учреждениеләрен кушу формасында үзгәртеп кору турында" 2017 елның 01 мартындагы 124 номерлы, "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Өлкән яшьтәге кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә" пилот проектын тормышка ашыру турында" 2016 елның 31 августындагы 604 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 08 декабрендәге 961 номерлы карарлары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "2017 елда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында" 2017 елның 13 февралендәге 74 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2017-2020 елларда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибен раслау турында";

1 пунктында "2017 елда" сүзләрен "2017-2020 елларда" сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта "Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методика үзәге" сүзләрен "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән

тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының республика ресурслар үзәге" сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән боерык белән расланган 2017 елда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2017-2020 елларда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибе";

Тәртипнең 1 пунктында "2017 елда" сүзләрен "2017-2020 елларда" сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2017-2020 елларда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибенә 1 нче кушымта";

"2017 елның _____№___ белешмә" сүзләрен "20___ елның ____ №__ белешмә" сүзләренә алмаштырырга";

Тәртипкә 2 нче кушымтада нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2017-2020 елларда өлкән яшьтәге гражданинны һәм тәрбиягә алучы гаилә төзергә теләге булган кандидатны психологик әзерләү тәртибенә 2 нче кушымта";

Министр Э.Ә.Зарипова